**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЯҢА ЧИШМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-20-08, факс: (8-84348) 2-21-73, Nsmsp.Nsm@tatar.ru

Бишенче чакырылыш
Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2026 елның 13 нче апреленнән

№ 6-22

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябрендә кабул ителгән 33-102 номерлы «яңа редакциядә, Яңа Чишмә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында» нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законы, Россия Федерациясе Президентының 2025 елның 31 декабрендәге 1009 номерлы Указы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Яңа Чишмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябрендәге 33-102 номерлы карары белән расланган « яңа редакциядә, Яңа Чишмә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында»гы Нигезләмәгә (10.03.2015 № 37-118; 26.12.2016 № 16-54; 15.03.2017 № 17-61; 6.07.2017 № 20-70; 10.11.2017 № 24-79; 18.05.2018 № 30-99; 26.03.2019 № 43-144; 12.09.2019 № 47-159; 11.03.2020 № 53-175; 15.06.2020 № 56-187; 18.02.2021 № 6-21; 6.07.2021 № 11-37; 29.06.2022 № 20-74; 10.03.2023 № 26-99; 17.08.2023 № 29-112; 28.03.2024 № 34-132; 22.11.2024 № 38-144; 20.12.2024 № 39-147; 30.10.2025 № 2-7 карарлары редакциясендә) (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 4.1 өлешендәге 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр;»;

1.2. Нигезләмәнең 3 бүлегендә:

а) 3.4 өлешнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19.1. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы граждан, муниципаль хезмәткәр әлеге Федераль законда билгеләнгән очракларда яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган белешмәләрне тапшыралар. Күрсәтелгән белешмәләр Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда

каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә, срокларда һәм формада тапшырыла.»;

б) 2 пунктта «керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 3 пунктта «керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне» сүзләрен «әлеге статья нигезендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне» сүзләренә алмаштырырга;

г) 4 пунктта «керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне» сүзләрен «әлеге статья нигезендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне» сүзләренә алмаштырырга;

д) 5 пунктта «чыгымнар керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне» сүзләрен «керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында» Федераль законда каралган белешмәләрне һәм «Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында», алыштарырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: https://novosheshminsk.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының социаль сәясәт һәм законлылык мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Яңа Чишмә авыл җирлеге Башлыгы Е.А. Тарнавский